Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАРЫ

8 август, 2025 ел № 7

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге территориясендә файдаланылган терекөмешле лампаларны туплау урыннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге территориясендә файдаланылган терекөмешле лампаларны җыюны оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Файдаланылган терекөмешле лампаларның туплану урынын, шул исәптән мондый туплану урыннарын оештыру мөмкин булмаган очракларда, күпфатирлы йортларда туплану урыннарын оештыру өчен урыннар булмау сәбәпле, Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге территориясендә, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Керәшен Сәрдәсе авылы, Татарстан урамы, 6а йорт адресы буенча терекөмешле лампаларны туплау урынын билгеләргә.

2. Файдаланылган терекөмешле лампаларны куркынычсыз туплауны тәэмин итү һәм аларны операторга тапшыру өчен җаваплы зат итеп Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.

3. Кулланучыларга файдаланылган терекөмешле лампаларны туплау урыннары турында мәгълүматны әйләнә-тирә мохит торышы турындагы федераль дәүләт мәгълүмати системасында урнаштыру юлы белән мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат бирергә.

4. Күпфатирлы йортларны идарә итү килешүе яки күпфатирлы йортлардагы биналарның милекчеләре белән төзелгән хезмәт күрсәтү һәм (яки) мондый йортларда гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау эшләрен башкару шартнамәсе нигезендә күпфатирлы йортларны идарә итүче юридик затларга (оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә) һәм шәхси эшмәкәрләргә, 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган, гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләре нигезендә, терекөмешле лампалар кулланучыларында файдаланылган терекөмешле лампаларны җыюны һәм туплауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге территориясендә файдаланылган терекөмешле лампаларны беренчел җыю урыннарын билгеләү турында» 2016 елның 24 мартындагы 6 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы Н.В. Морозов